МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.12.2022 Казан ш № 1077

2023 елда бер экспертиза объектына карата хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү өчен түләү күләмен раслау турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 213 статьясы, «Хезмәт шартларын махсус бәяләү турында» 2013 елның 28 декабрендәге 426-ФЗ номерлы федераль законның 24 статьясындагы өченче өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү тәртибен раслау турында» 2021 елның 29 октябрендәге 775н номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 елның 11 июнендәге 431 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. 2023 елда бер экспертиза объектына карата хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү өчен 1 нче кушымтага туры китереп түләү күләме расларга.
2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) хезмәтне саклау буенча дәүләт идарәсе бүлеген хезмәт шартларына махсус бәяләү уздыру максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрүгә вәкаләтле итеп билгеләргә.
3. Билгеләргә:

хезмәт шартларына махсус бәяләү уздыру сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына экспертиза үткәрү объекты булып хезмәт шартларына карата хезмәт шартларына махсус бәяләү уздырылган эш урыны тора;

хезмәт шартларына махсус бәяләү уздыру сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәргән өчен мөрәҗәгать тарафыннан түләү акчасыз түләү формасында, хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру турындагы гаризаны Министрлыкка тапшырганчыга кадәр Татарстан Республикасы бюджетына акча күчерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4. Хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәргән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү күчерү өчен банк реквизитларын 2 нче кушымтага туры китереп билгеләргә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары Р.Ф.Вәлиулловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2022 елның
6 декабрендәге 1077 номерлы
карарына 1 нче кушымта

2023 елда хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасының бер объектына карата түләү күләме

| т/с | Эшләр төре | Эш урыннары, берәмлек | Бер эш урыны өчен түләү күләме, сум |
|---|---|---|---|
| 1. | Хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү | 1 - 5 | 13 371,95 |
| | | 6 - 50 | 20 057,93 |
| | | 50 артык | 26 743,91 |
| 2. | Эш урынын (эш урыннарын) тикшерү өчен эш урыннарына чыгып (тәүлеклек эшләрне һәм яшәү шартларын исәпкә алып) хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү | 1 - 5 | 44 103,60 |
| | | 6 - 50 | 66 155,40 |
| | | 50 артык | 88 207,21 |

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2022 елның
6 декабрендәге 1077 номерлы
карарына 2 нче кушымта

**Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын түләү өчен реквизитлар хезмәт шартларына махсус бәя бирү сыйфатын бәяләү максатларында**

**Алучы** Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (Татарстан Республикасы хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, л/с 04112001150)

**ИНН/КПП** 1657069000/165701001

**БИК** 019205400

**Банк** Татарстан Республикасы Россия банкы / /Татарстан Республикасы буенча ФК Казан шәһәре

**Корреспондент исәбе** 40102810445370000079

**Расчет исәбе** 03100643000000011100

**ОКТМО:** шәһәр (район) буенча теркәлү урыны буенча

**Бюджет классификациясе коды:** 716 1 13 01992 02 0000 130

**Түләү билгеләү:** Хезмәт шартларына махсус бәя бирү сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздырган өчен.